**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**

08.04.2020 — № 178

**Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының «Тәтеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләре территорияләрен планлаштыру проектларын, территорияне межалау проектларын әзерләү, территорияне планлаштыру проектларын, межалау проектларын тикшерү һәм раслау тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 2018 елның 22 ноябрендәге 658 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының «Тәтеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләре территорияләрен планлаштыру проектларын, территорияне межалау проектларын әзерләү, территорияне планлаштыру проектларын, межалау проектларын тикшерү һәм раслау тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 2018 елның 22 ноябрендәге 658 номерлы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кушымтаның 2.2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә «Федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектларны проектлау чикләрендә урнаштырганда, шулай ук, Тәтеш муниципаль районы шәһәр төзелеше проектлаштыруның региональ нормативлары нигезендә, муниципаль берәмлек халкы өчен көндәлек хезмәт күрсәтү объектлары белән тәэмин ителешнең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсен һәм мондый объектларның һәркем өчен мөмкин булуын билгеләү максатларында, территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү йөкләмәсе нигезендә тиешле килештерү яки бәяләмәләр үткәрелә. Бу очракларда вәкаләтле федераль, региональ дәүләт хакимияте

органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан проектның федераль, региональ һәм җирле территориаль планлаштыру документларына туры килү-килмәве турында килешү бирелергә тиеш. Килештерүче органнар исемлеге территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү биремендә билгеләнергә тиеш.

Муниципаль районның территориаль планлаштыру схемасы нигезендә проект әзерләгәндә, проект Тәтеш муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән килештерелергә тиеш.

Дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләре алу рөхсәт ителә торган федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру проекты, РФ Шәһәр төзелеше кодексында каралган очрактан тыш, дәүләт хакимияте органы яки җирле үзидарә органы белән раслангачны, дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен алу турында карар кабул итүгә вәкаләтле орган белән килештерелергә тиеш. Территорияне планлаштыру проектын күрсәтелгән дәүләт хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы белән килештерү предметы федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен планлаштыру проектында каралган чикләрдән гыйбарәт».

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU.) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Ф. Әхмәтшинга йөкләргә.

**Тәтеш муниципаль районы**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **А.Б. Семенычев**